Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге Мамык авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«22» ноябрь 2020 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 22 ноябрендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, яшәү урыны буенча теркәлгән, әмма яшәмәгән гражданнарнардан тыш, 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Торак пункт чикләрендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту, асфальт юлның чокырларын ямау, юл кырыйларына бут ташы, ватык кирпеч, грунт, вак таш, ком түшәү (сатып алу, ташу, җәю)
Мамык авылы.
- Су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү;
- Урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен эшләр һәм хезмәтләр, товарлар сатып алу;
- Мамык авылында ике җәяүлеләр күперен ремонтлау (өслеген алыштыру, буяу, материал сатып алу);
- Мамык авылында "Җиңү" паркын төзекләндерү (Бөек Ватан сугышында катнашучыларга куелган һәйкәл каршында брусчатка сатып алу һәм урнаштыру, койманы ремонтлау)» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 802 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 490 кеше катнашты.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 381 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 109 катнашучысы тавыш бирде.
Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:
1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге Мамык авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр

инвалидлардан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, яшәү урыны буенча теркәлгән, әмма яшәмәгән гражданнарнардан тыш, 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Торак пункт чикләрендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту, асфальт юлның чокырларын ямау, юл кырыйларына бут ташы, ватык кирпеч, грунт, вак таш, ком түшәү (сатып алу, ташу, җәю)

Мамык авылы.

- Су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү;

- Урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен эшләр һәм хезмәтләр, товарлар сатып алу;

- Мамык авылында ике җәяүлеләр күперен ремонтлау (өслеген алыштыру, буяу, материал сатып алу);

- Мамык авылында "Җиңү" паркын төзекләндерү (Бөек Ватан сугышында катнашучыларга куелган һәйкәл каршында брусчатка сатып алу һәм урнаштыру, койманы ремонтлау)» мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Мамык авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: В.В. Рыжков

Мамык авыл җирлеге башлыгы В.В. Рыжков